

**Фахразиева Силүзә Котдус кызы** Актаныш районы Түке авылында, 1966 нчы елның 12 нче июнендә туган. 1973 нче елда Актаныш районы Туке авылында башлангыч белем ала. 1983 нче елда Пучы урта мәктәбен тәмамлый.

1983-1986 нчы уку елларында Яр Чаллы педагогия училищесын тәмамлап, Актаныш районы Туке авылында балалар бакчасы мөдире вазыйфасын башкара. 1989 нче елдан-2004 нче елларда ,,Ләйсән" балалар бакчасында тәрбияче булып эшли.

2004-2010 нче елларда ,,Кояшкай " балалар бакчасына тәрбияче итеп күчерелә

2013-2016 нчы уку елларында Чаллы педагогия институтында югары белем ала.

2010 нчы елда янәдән , "Ләйсән" балалар бакчасында эшли башлый. Яңалыкка омтылып эшләүче, җәмгыятьтә бара торган үзгәрешләрне кабул итеп, заман белән бергә атлаучы, заманча белеи бирү технологияләреннән киң файдаланып эш итүче тәрбиячеләрның берсе. 30 ел гомерен балаларга белем һәм тәрбия бирүгә багышлаган, күпсанлы Мактау грамоталарына, " Татарстан Республикасының күкрәк билгесе " нә лаек булган югары категорияле Силүзә Котдус кызы бүгенге көндә дә Мөслим "Ләйсән" балалар бакчасында хезмәт куя.



**Имамова Розалия Миргазиян кызы** югары белемле, беренче категорияле тәрбияче. Ул 1968 нче елны 4 нче ноябрендә Мөслим районы Иске Әлмәт авылында Клара һәм Миргазиян Шәйхәйдаровлар гаиләсендә, өченче бала булып дөньяга килә.

Ул үзенен хезмәт юлын балалар тәрбияләүгә багышлый. Педагогик белемне Минзәлә педагогия училищесында башлангыч классклар һәм тәрбияче белгечлеге буенча ала. Соңыннан Казан (Идел буе) дәүләт университетын читтән торып тәмамлый.

Аның педагогик эшчәнлеге 1988 нче елда башлана. Тукай районы Калмаш авылында башлангыч класслар укыта.

2001 нче елда Мөслимгә кайталар. Монда ул ГПТУның тулай торагында тәрбияче булып эшли.

2008 нче елдан бүгенге көнгә кадәр "Ләйсән" балалар бакчасында тәрбияче булып хезмәт куя. Эшләү дәверендә Розалия Миргазиян кызы төрле конкурсларда катнашып район Мәгариф бүлегенең Мактау грамотасы һәм Рәхмәт хатлары белән бүләкләнде. (2010 нчы елда Юл хәрәкәтен өйрәтү буенча "Яшел ут" конкурсында катнашып мәгариф идәрәсенең Рәхмәт хаты, 2012 нче елда "Ел тәрбиячесе" конкурсына катнашып мәгариф идәрәсенең Мактау грамотасы, "Әкият мотивында коврабук" конкурсында 2нче урын, 2019 нчы елда "Ел тәрбиячесе" конкурсында 3 нче урын, "Бизиборд" конкурсында 1 урын алып район Мәгариф бүлегенең Мактау грамотасы һәм Рәхмәт хатлары белән бүләкләнде. Балалары белән дә район, республикакүләм ярышларда да актив катнашып район Мәгариф бүлегенең Мактау грамотасы һәм Рәхмәт хатлары белән бүләкләнәләр. "Сәйяр" театр конкурсында Мәгариф һәм фән министрлыгының дипломына лаек булдылар. 2020 нчы елда, Яшь буынга белем һәм тәрбия бирү системасына керткән зур өлеше, күпьеллык намуслы хезмәте өчен ТР Мәгариф һәм Фән министрының Мактау грамотасы белән бүләкләнде.




**Эльмира Васил кызы Тимергалиева** 1964 нче елның 26 нчы июнендә Минзәлә районы Бикбау авылында туган. 1979нчы елда сигез классны тәмамлаганнан соң, Минзәлә педагогия училищесына укырга керә һәм укуны тәмамлаганнан соң, Мөслим районы Әмәкәй авылына башлангыч класслар укытучысы итеп эшкә билгеләнә. Эльмира Васил кызы үзенең тормыш иптәше Мөдәрисне дә шушы авылда очрата.

1990 нчы елның январендә ул “Ләйсән” балалар бакчасына эшкә килә. Шул елны ул читтән торып Казан дәүләт педагогия университетынын “Татар теле һәм әдәбият” бүлеген тәмамлый.

“Ул дәвердә уенчыклар булмау сәбәпле, балалар йоклаган вакытта да кулдан “папье маше” ысулы белән төрле уенчыклар, алдагы эшчәнлек өчен күрсәтмә материаллар ясау, уен почмакларын үзенә тартып торырлык итеп, зәвек белән буяу, ясау минем максатым иде, -дип искә алды Эльмира Василовна.

1995нче елда ул икенче номерлы мәктәпкә татар теле һәм әдәбияты укытучысы итеп күчерелә.Хәзерге көндә Мөслим гимназиясендә эшли.



**Хайретдинова Әминә Мизхәт кызы** 1964нче елның 12 нче ноябрендә Мөслим районы Тойгелде авылында туа. Үзенең хезмәт юлын Мөслим «Ләйсән» балалар бакчасында 1987 нче елның 30 нчы ноябреннән, бакча ачылу эшләреннән башлап җибәрә.Тәрбияче ярдәмчесе вазыйфасында 2005 нче елга кадәр хезмәт куя. Балалар бакчасы ябылу сәбәпле, «Миләшкәй» балалар бакчасына күчерелә. Бүгенге көндә дә «Миләшкәй» балалар бакчасында эшләвен дәвам итә.



**Шәрәфутдинова Лилия Даннур кызы** 1967 нче елның 2 нче маенда Мөслим авылында туа. 10 нчы классны тәмамлагач, 1984 нче елда класс белән «Киров» исемендәге колхозда эшкә кала. 1986 нче елда Яр Чаллы шәһәре педагогия институтына укырга керә. 1990 нчы елда институтны тәмамлап, Мөслим НПС оешмасына караган «Ләйсән» балалар бакчасына эшкә керә. 1991 нче елда «Карлыгач» балалар бакчасына укытучы-логопед булып күчә. 2006 нчы елдан бүгенге көнгә кадәр «Миләшкәй» балалар бакчасында логопед булып эшли..



**Сөләйманова (Пискунова) Элмира Фазаел кызы** 1976 нчы елның 10 нчы мартында Мөслим районы Вәрәшбаш авылында туа.

Мәктәпне тәмамлагач, Яр Чаллы педагогика институтының мәктәпкәчә яшьтәге балаларны тәрбияләү һәм белеем бирү бүлегендә укый. Читтән торып КДПУ да педагог-психолог һөнәрен үзләштерә. 1997-2000 нче елларда Мөслим авылы «Ләйсән» балалар бакчасында педагог-психолог булып эшли. Хәзерге көндә Элмира Фазаел кызы Чаллы шәһәрендә яши.



**Гардисламова Альбина Әхияр кызы** 1969 нчы елның 20 нче апрелендә Мөслим районы Каенсаз авылында туа. 1987- 2002 нче елларда Мөслим “Ләйсән” балалар бакчасында тегүче булып эшли. Бакча бинасы эчендәге стеналардагы барлык рәсемнәрне Альбина Әхияровна уз куллары белән ясап, бизи. Күпләр ул тудырган матурлыкны хәзерге көндә дә сагынып искә алалар, сөйлиләр.



**Уразаева Рәмилә Галимҗан кызы** 1962 нче елнын 14 маенда Актаныш районы, Пучы авылында туа. Урта мәктәпне тәмамлагач, Түбән Кама педагогия көллиятенә укырга керә. Укуны тәмамлаганнан соң,1985 елда Мөслим районы, Мөслим авылына тәрбияче булып кайта. Хезмәт юлын Мөслим "Кояшкай" балалар бакчасында башлап җибәрә. 1987 нче елда Мөслим нефть кудыру станциясе житәкчелегендә ачылган "Ләйсән" балалар бакчасына тәрбияче булып күчә. Рәмилә Галимжановна куп тапкырлар мәгариф бүлегенең Мактау кәгазьләренә лаек була, 1995 нче елда Россия Федерациясенең "Халык мәгариф отличнигы" күкрәк билгесе белән бүләкләнә. Күп еллар район мәгариф бүлегендә аттестация комиссиясе әгъзасы булып тора. Банк сайлау участогында сайлаулар вакытында күп еллар сәркатиб булып эшли. 2000 нче елда читтән торып, Яр Чаллы педагогия институтының мәктәпкәчә бүлеген тәмамлап, югары белем ала.

2003 нче елдан "Ләйсән" балалар бакчасы мөдире булып эшли.2005 нче елда“Ләйсән” балалар бакчасы ябылу сәбәпле, Рәмилә Галимҗановна педагогик эшен Мөслим “Кояшкай” балалар бакчасында дәвам итә, 2019 нчы елдан лаеклы ялда.



**Хамматуллина Валентина Прокопьевна** 1963 нче елның 26 нчы маенда Яңа Усы авылында туган.

Мөслим урта мәктәбендә укыганда, 1978 нче елда Лениногорск педагогика училищесының музыка бүлегенә укырга керә, 1982 нче елны "җыр укытучысы һәм музыка тәрбиячесе" квалификациясе белән тәмамлый.

1982 нче елда Менделеевск шәһәренең интернет - мәктәбенә укырга җибәрелә, әмма Бөек Ватан сугышы ветераны, әнисе Евдокия Роман кызы Егоровның туган апасы Евдокия ялгызы калу сәбәпле, ул Мөслимгә әйләнеп кайта, һәм ул Мөслимнең 2 нче балалар бакчасына музыка җитәкчесе итеп билгеләнә. Бередә 3 ел эшләп, балалар сәнгать мәктәбенә халык уен кораллары (баян) укытучысы итеп билгеләнә һәм параллель рәвештә шул ук балалар бакчасында эшен дәвам итә.

1987 нче елның декабрендә яңа "Ләйсән" балалар бакчасы ачыла, анда музыка җитәкчесе итеп кабул ителә.

2005 нче елда "Ләйсән" балалар бакчасы ябылу сәбәпле, Валентина Прокопьевна Мөслимнең "Кояшкай"балалар бакчасына музыка җитәкчесе итеп күчерелә.

2006 нчы елның сентябреннән 2008 нчеелның ахырына кадәр "Миләшкәй" балалар бакчасында эшли. Ә 2008 нче елның сентябрендә кабаттан "Кояшкай" балалар бакчасына әйләнеп кайта.Эш дәверендә ул мәдәният бүлегенең, Мәгариф бүлегенең күпсанлы грамоталары белән бүләкләнә. 2012 нче елда - "ТР мәгарифендәге казанышлары өчен" күкрәк билгесе, 2017 нче елда-РФ Мәгариф Министрлыгының Мактау грамотасы белән бүләкләнә.

Хәзерге вакытта "Сүнмәс дәрт" ветераннар коллективының хатын-кызлар вокаль ансамбле җитәкчесе булып тора,. Валентина Прокопьевна 2020 елда лауреат булды һәм Татарстан Республикасы ветераннары арасында "Балкыш"VI Республика үзешчән башкаручылар фестиваленең дипломы белән бүләкләнде.



**Рәйсә Гафур кызы Фәхразиева** 1955 нче елның 6 нчы апрелендә Кемерово өлкәсе Осинники шәһәрендә шахтер гаиләсендә икенче бала булып дөньяга килә. Озакламый Актаныш районы Чуракай авылына күчеп кайталар. Ул шунда сигез класс белем ала. Минзәлә педагогия училищесына укый, укуны тәмамлаганнан соң, Мөслим районы Әмәкәй авылы балалар бакчасына тәрбияче итеп эшкә билгеләнә. Үз эшенең остасы баянда уйный, оста рәссамчы да. Уңган кызны тиздән комсомол секретаре итеп билгеләп куялар, агитатор хезмәте дә йөкләнә. Иҗади эшләүче, оештыру сәләте көчле булган тәрбиячене бакча мөдире итеп куялар.

1980 нче елда алар гаиләләре белән Мөслимгә күчеп киләләр һәм мәктәптә 6 яшьлек балалар өчен эксперименталь әзерлек төркемнәрендә эшли башлый.

6 яшьлекләрнең әзерлек төркеме бетерелгәч, озайтылган көн төркеме тәрбиячесе һәм пионер вожатый эшен дә башкара Рәйсә Гафур кызы . Мәгариф идарәсенең Мактау кәгазьләре белән бүләкләнә. Район методик берләшмәсе җитәкчесе була.

Рәйсә Фәхразиева 1994 нче елдан 2010 нчы елга кадәр Мөслим“Ләйсән” балалар бакчасында югары категориягә ия тәрбияче булып эшләи.

Эшләү дәверендә район һәм республикакүләм конкурсларда актив катнаша.

Үзеннән соңгы буын тәрбиячеләргә ярдәмгә “Балалар бакчасында ата-аналар белән эшләү алымнары”, “Балалар өчен мавыктыргыч уеннар", “Математика шөгылендә яңа технологияләр куллану” исемле методик ярдәмлекләр чыгарды. Район газетасында да аның шактый материаллары дөнья күрде.

Намуслы хезмәтләре өчен, ул район Мәгариф бүлегенең Мактау кәгазьләре һәм Рәхмәт хатлары, РФ Мәгариф һәм фән министрлыгының Мактау кәгазе белән бүләкләнәХәзерге көндә лаеклы ялда.



**Фазлыева Зәнфирә Миргарифан кызы** 1957 нче елның 22 нче гыйнваренда Мөслим районы, Вәрәшбаш авылында беренче бала (4 бала) булып гади эшчеләр гаиләсендә туган. 1964-1974 нче елларда Мөслим урта мәктәбендә уку аттестаты ала. 1974-1979 нчы елларда Алабуга педагогия институтының филология бүлегендә укый. Татар теле һәм әдәбияты, рус теле һәм әдәбияты укытучысы белеме алып чыга. 1979 нчы елда Симәк урта мәктәбенә рус теле һәм әдәбияты укытучысы итеп билгеләнә. 1986-1991 нче елларда район мәгариф бүлегендә балалар хокукын яклау буенча инспектор булып эшли. 1991-2005 нче елларда Мөслим“Ләйсән” балалар бакчасына тәрбияче булып эшли. 2005 нче елда “Ләйсән”балалр бакчасы ябылу сәбәпле,”Кояшкай “балалар бакчасына тәрбияче итеп күчерелә. 2005-2012 нче елларда Мөслим“Кояшкай” балалар бакчасында тәрбияче булып,тырышып хезмәт итә. 2012 нче елда лаеклы ялга чыга.



**Петряева (Дәүләтбаева) Елена Минлегәрәй кызы** 1960 нчы елның 8 нче сентябрендә Мөслим районы Калтак авылында туган. Туган авылы Калтакта сигезеллык мәктәпне тәмамлагач, Түбән Кама шәһәренең 53 нче һөнәр училищесында белем ала. Укуын тәмамлагач, Түбән Кама шәһәренең төрле төзелеш оешмаларында буяучы (маляр) булып эшли. 1986-1989 нче елларда Саратов шәһәрендә яши.

1989 – 1993нче елларда яңа төзелгән «Ләйсән» балалар бакчасында тәрбияче ярдәмчесе булып хезмәт юлын дәвам итә. Соңрак 1993-2003 нче еллар аралыгында Мөслим үзәгендә урнашкан «Карлыгач», Керәшен Шуран авылының «Дуслык» балалар бакчасында пешекче булып эшли.

Тормыш иптәше белән бер кыз, ике малай тәрбияләп үстергәннәр, биш оныклары бар.

Бугенге көндә лаеклы ялда, Мөслим авылында гомер кичерә.



**Зиатдинова Сажидә Зөфәр кызы** 1955 нче елның 24 гыйнварендә Мөслим районы Югары Табын авылында туган.

Мәллә-Тамак урта мәктәбен тәмамлагач, Мөслим КБОсында тегүче булып эшли .

1976 нчы елда Вәрәшбаш авылы егетенә кияүгә чыгып, 3 бала тәрбияләп үстерәләр.

1989 нче елда Мөслимгә күченеп килеп, "Ләйсән" балалар бакчасында тәрбияче ярдәмчесе булып эшли башлый. Бакчада 1996 нчы елга кадәр эшли.

1996 нче елда налоговыйда техник хезмәткәр булып эшли.

2009 нчы елдан кабаттан Мөслим "Ләйсән" балалар бакчасына пешекче булып эшкә урнаша.Тәмле ризыклар пешерүче Сажидә Зөфәр кызы хз эшенең остасы була.

2010 нчы елның сентябреннән лаеклы ялда.



**Солтанова Ризида Зөфәр кызы** 1960 нчы елның 4 нче августында Мөслим районы Тугаш авылында туган.1977 нче елда мәктәпне тәмамлагач, 1998 нче елга кадәр хуҗалык хисап берләшмәсенең җәмәгать тукулануы предприятиясендә пешекче-кондитер булып эшли. 1983 нче елны Казан шәһәрендә “Татпотребсоюз” берләшмәсендә укып , IV нче разряд кондитер квалификациясен ала. 1998 нче елдан 2006 нчы елга кадәр АООТ “Сельхозтехника”да пешекче-кондитер булып эшли.

2014 нче елдан Мөслим “Ләйсән” балалар бакчасына ашханә эшчесе итеп алына. 2015 нче елдан лаеклы ялда.



**Сабирова Гүзәлия Рамил кызы** 1989 нчы елның 30 нчы апрелендә Мөслим районы Мөслим авылында туа.1996 - 2007 нче елларда Мөслим урта белем бирү мәктәбендә белем ала.Мәктәпне тәмамлагач,Минзәлә педагогия училищесының мәктәпкәчә яшьтәге балаларга белем бирү бүлегендә белем ала.2011 нче елда Мөслим “Ләйсән” балалар бакчасына тәрбияче ярдәмчесе булып эшкә урнаша.



**Гаттарова Айгөл Фирдавес кызы** 1985 нче елда Мөслим авылында туган. Икенче номерлы Мөслим Урта мәктәбен тәмамлагач, һөнәри белем бирү көллиятендә укып, 2004нче елда умартачы һөнәрен үзләштерә. 2008 нче елның сентябрендә “Ләйсән” балалар бакчасына техник эшче булып эшкә урнаша. 2014 нче елның мартында кер юуычы вазифасына күчерелә, 2015 - 2017 нче елларда тәрбияче ярдәмчесе булып эшли.Хәзерге көндә “Кояшкай” балалар бакчасында тәрбияче ярдәмчесе булып эшли.



**Шакирова (Харисова) Рәфизә Мыхаматхан кызы** 1965 нче елның 15нче июлендә Мөслим районы Урәзмәт-Чишмә авылында туган.

Хезмәт юлын 1983нче елда пешекче буларак башлый. .

1987 нче елның 30 нчы ноябрендә НПС оешмасында эшләгән эшчеләрнең балалары өчен төзелгән «Ромашка» балалар бакчасында эшли башлый. 1989 нче елның 30 нчы нояберенә кадәр әлеге бакчада пешекче хезмәтен башкара

Бүгенге көндә Үрәзмәт авылында яши.



**Мингазова Илгизә Әхтәмгали кызы** 1959 нчы елның 4 августында, Мөслим районы Мөсәгәт авылында дөньяга килгән. Мәктәпне тәмамлагач, Маслозавод буенча училищега керә, мастер булып эшли.

1989 нчы елда “Ләйсән” балалар бакчасына эшкә керә. Илгиза Мингазова башта техник хезмәткәр, ә соңыннан пешекче булып эшли. “Ләйсән” балалар бакчасында 13 ел гомерен балаларны тәмле ризыклар белән сыйлауга багышлый. Хәзерге көндә лаеклы ялда.



**Валеева Рима Александр кызы** 1946 нчы елның 10 нчы августында Мөслим районы Яңа Усы авылында туа. 1987 нче елның 7 нче декабрендә “Ләйсән” балалар бакчасына пешекче ярдәмчесе булып эшкә урнаша. 2002 нче елның 8 нче июлендә лаеклы ялга китә.



**Яхина Фәрсия Сабирҗан кызы** Актаныш районы Колын авылында 1960 нчы елның декабрь аенда туган. 1978 нче елда Туган авылы мәктәбен тәмамлап, завод СОМга эшкә керә .1984 нче елда Воронежда укып кайткач,сату системасында эшли.1987 нче елның 1 нче ноябрендә НПС “Ләйсән” балалар бакчасына кер юучы булып эшкә керә. 1990 - 2005 нче елларда “Ләйсән”балалар бакчасында пешекче хезмәтен башкара.2005 нче елның май аенда “Миләшкәй” балалар бакчасына күчерелә. 30 ел гомрен балаларга тәмле ризыклар пешерүгә багыәлый. Бүгенге көндә лаеклы ялда.



**Мирзаянова Ләлә Флюн кызы** 1969 нчы елың 6 нчы июнендә Мөслим районы Карл Либкнехт авылында туган.

1975-1986 нче елларда Мөслим урта мәктәбендә белем алып,1988-1990 нчы елларда Чаллы шәһәрендә 67 нче санлы урта профессиональ техник училищесын тәмамлап, 3 нче разрядлы кондитер һөнәрен ала.

Тормыш иптәше Мирзаянов Алмаз белән бер кыз, бер малай тәрбияләп үстерәләр. Кызлары югары белем алып, Чаллы шәһәрендә автомеханический техникумда педагог булып эшли. Уллары читтән торып Алабуга шәһәрендә КФУ да белем ала.

1990 нчы елдан бирле үз һөнәренә тугры калып повар-кондитер булып эшли.2003-2005 нче елларда “Ләйсән” балалар бакчасында, хәзерге көндә Мөслим лицеенда повар- кондитер булып эшләвен дәвам итә.

2020 нчы елда Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы башлыгының мактау грамотасы белән бүләкләнә.



**Гардиханова Әлфинә Камалетдин кызы** 1959 нчы елның 17 нче августында Мөслим районы Татар Бүләр авылында туа.

1987 нче елның 1 нче декабреннән “Ромашка” балалар бакчасында тәрбияче булып эшли, соңыннан Мөслим Үзәк шифаханәсенә шәфкать туташы булып күчә.



**Садретдинова Гөлнара Роберт кызы** 1965 нче елның 6 нчы августында Мөслим авылында туа. 1982-84 нче елларда Чаллы медицина училищесында укый.

1987- 1991нче елларда “Ләйсән” балалар бакчасында тәрбияче булып эшли. 1991нче елдан бүгенге көнгә кадәр Мөслим «Карлыгач» балалар бакчасында шәфкать туташы.



**Сафина Алсу Шәрәп кызы** 1955 нче елның 15 нче февралендә Бавлы районы Салих авылында 2 бала булып хезмәткәрләр гаиләсендә туа.

1963 нче елда Салих авылы башлангыч мәктәбенә укырга керә. Авылда башлангыч мәктәп кенә булу сәбәпле, урта белемне 1967 нче елда күрше Иске Чутин авылында алырга туры килә. Монда ул сигез классны тәмамлап, 1970 нче елда Минзәлә медицина училищесына укырга китә.

1974 нчы елда училищены тәмамлап, Бавлы районы Иске Чутин авылыны фельдшер пунктына эшкә кайта.

1975 елдан Яр Чаллы шәһәренә китү сәбәпле, ул 1977 елга кадәр Чаллыдагы ашыгыч ярдәм станциясендә эшли.

1978 - 1979 нчы елларда Круглое поле станциясендә фельдшер булып эшли.

1979 нчы елда Мөслим районына кияүгә чыга һәм хезмәт юлын Мөслим санэпидстанциясендә санитар. табиб ярдәмчесе булып эшли башлый.

1985 - 1987 нче елларда район үзәгендәге "Аленушка" балалар бакчасында шәфкать туташы булып эшли.

1987 нче елдан Мөслимдә НПС (нефтеперекачивающая станция) оешмасына караган өр-яңа "Ләйсән" балалар бакчасына шәфкать туташы булып күчә.

2005 нче елда "Ләйсән" балалар бакчасы ябылу сәбәпле, "Миләшкәй" балалар бакчасына шәфкать туташы булып күчә.

2008 нче елдан "Ләйсән" балалар бакчасы, яңадан ачылу сәбәпле ул лаеклы ялга киткәнче, 2012 нче елга кадәр шушы бакчада хезмәт куя.

Шушы күп еллар фидакәрь эшләү нәтиҗәсе булып, Алсу Шәрәп кызы бик күп кенә мактау кәгазьләре, мактау грамоталары, "Хезмәт ветераны" билгеләре белән бүләкләнә.

Лаеклы ялга чыкса да, Алсу Шәрәп кызы 2015 нче елга кадәр "Миләшкәй" һәм "Ләйсән" балалар бакчаларында вакытлыча хезмәт куя.

Хәзерге көндә Мөслим авылында яши.



**Гимранова Кадрия Нәби кызы** Азнакай районы Мендей авылында 1962 нче елның 13 нче май аенда туган. 1969 нчы елда мәктәпкә укырга керә. Укуын тәмамлагач, 1979 нчы елны Бөгелмә медицина училищесында укый, 1982 нче елны укуны тәмамлый.

1982 нче елдан 1984 нче елга кадәр Метрәй авылында фельдшер булып эшли.

1984 нче елдан Мөслим авылына поликлиникага эшкә килә. Бик күп еллар үз хезмәтен яратып башкара.

2012 нче елдан Ләйсән балалар бакчасына медсестра булып эшкә килә.

2017 нче елда лаеклы ялга китә.



**Хәснетдинова Римма Александр кызы** 1950 нче елның 28 нче июлендә Бакалы районы Умеров авылында дә туа.


Бик күп еллар Мөслим “Ләйсән” балалар бакчасында каравылчы булып эшли.



**Мәвлиева Әлфия Галимҗан кызы** 1958нче елының 30нчы августында Актаныш районы Пучы авылында дөньяга килә. 1965-1967 нче елларда Пучы урта мәктәбен тәмамлый. 1975 – 1976 нчы еллларда Казан ГППУ -19 уку йортында белем ала. 1976 - 1979 нчы елларда Куйбышев исемендәге Казан химия заводында эшли. 2000 елда “Ләйсән” балалар бакчасына кер юу штатына билгеләнә. 2005 нче елда “Ләйсән” балалар бакчасы ябылу сәбәпле, “Кояшкай” балалар бакчасына күчерелеп, хезмәт юлын шунда дәвам итә. Бугенге көндә лаеклы ялда.



**Бикмурзина Ирина Арслан кызы** 1964 нче елның 10 нчы апрелендә Мөслим районы Усаклы авылында туган. Мәктәне тәмамлагач, Мөслим “Ләйсән” балалар бакчасына эшкә килә. 1991-2005 нче елларда техник хезмәткәр булып эшли Үзенең тырышлыгы, чисталыкны, хезмәтне яратуы белән аерылып тора Ирина Арслан кызы коллективта.2005нче елда “Ләйсән”балалар бакчасы ябылу сәбәплКояшкай”балалар бакчасына күчерелә,бүгенге көндә дә ул шунда хезмәтен дәвам итә



**Харисов Әмирхан Михәмәтхан улы** 1958 нче елның 13 нче сентябрендә Мөслим районы Урәзмәт Чишмә авылында туган.

1966 нчы елны Урәзмәт Чишмә башлангыч мәктәбенә укырга кереп, 1976 елны Урәзмәт урта мәктәбен тәмамлаган.

1976 - 1978 нче елларны Совет Армиясендә хезмәт иткән.

1978 -1982 нче елларда Түбән Кама шин заводында вулканизатор булып эшләгән.

1982 нче елда Мөслим районы Урәзмәт авылына кайтып 1997 елга кадәр Урәзмәт авылының Карл Маркс исемендәге колхозда механизотор булып эшләгән.

1997 – 1999 нчы елларда Мөслим районының Бүләк авылындагы ярдәмче хуҗалыкта хезмәт куйган.

1999 -2003 нче елларда район үзәгендә булган ашлык кабул иту пунктында механизатор булып эшләгән. 2003 - 2005 нче елларда "Ләйсән" балалар бакчасында каравылчы булып эшли



**Петров Альберт Виниямин улы** 1954 нче елның 1 нче маенда Мөслим районы Иске Карамалы авылында туа. 1971-1974 нче елларда завод СОМ да эшли. 1981- 2000 нче елларда һәйкәлләр ясау цехында хезмәт куя. 2010-2015 нче елларда Мөслим “Ләйсән” балалар бакчасында каравылчы булып эшли. “Каравылчының эш сәгате бакчаның эш сәгате беткәч, 17.30 башланып, икенче көннең иртәнге 7.00 сәгатькә кадәр иде, эштә барлык җирдә тәртип булуын карап, бакчаның иминлеген саклый идем, - дип”, искә ала Альберт абый.



**Гафурова (Тимкина) Индира Дамир кызы** 1972 нче елның 13 нче июлендә Мөслим районы Иске Карамалы авылында икенче бала булып дөньяга килә.

1989-1991 нче елларда культура училищасының хореография бүлеген тәмамлап, 1992-2010 нчы елларда Мөслим мәдәният йортының хореография бүлегендә хезмәт куя. 2010-2017 нче елларда Мөслим авылы «Ләйсән» балалар бакчасында балаларга музыка тәрбиясе бирә. Хәзерге көндә Индира Дамир кызы Мөслим районы Зифа Басыйрова исемендәге мәдәният йортында хореография бүлегендә эшләвен дәвам итә. Нәтиҗәле хезмәт куйган өчен 2019 нчы елда Мөслим мактау тактасына портреты куелды. 2018 нче елда муниципаль район башлыгының мактау грамотасы, 2019 нчы елның май аенда Татарстан Республикасы мәдәният министрлыгының мактау грамотасы белән бүләкләнде.



**Адиятуллина Гөлнар Илфат кызы** 1987 нче елның 31 нче декабрендә Мөслим районы Мөслим авылында иҗади гаиләдә туып үсә. “Кечкенәдән үк музыка тыңлап, матур әдәбият укып үстем,”- ди ул. Яшь чактан җыр – моңга битараф булмаган кыз мәктәпне тәмамлагач, Лениногорск шәһәре музыка-сәнгать педагогия училищесында 4 ел белем ала. Балалар белән эшләү теләге Гөлнар Илфат кызының икенче зур хыялы була.  “Кеше һөнәрне түгел, ә һөнәр кешене сайлый”- дип язган Сократ. 2013 нче елда ул «Ләйсән” балалар бакчасында музыка җитәкчесе булып эшли башлый. “Шулай итеп һөнәр мине үзе эзләп тапты. Очраклы гына тәрбияче булып килеп кереп, балалар бакчасында эшләп булмый”-, ди ул. “Ләйсән” балалар бакчасында 4 ел балаларга музыка буенча белем бирә. Хәзерге көндә  Әлмәт шәһәрендә яши.



**Заянова Лилия Рафис кызы** 1979 нчы елнын 15 нче августында Мөслим районы Метерәй авылында игезәк кызлар булып дөньяга киләләр.1996-2000 нче елларда Лениногорск педагогия училищесының музыка факультетын тәмамлап, 2000-2005 нче елларда читтән торып Мәскәү дәүләт мәдәният сәнгать университетында югары белем ала.

2000-2003 нче елларда  Мөслим районы “Миләшкәй” балалар бакчасында музыка житәкчесе, 2003-2008 нче елларда Мөслим авылы «Карлыгач» балалар бакчасында музыка җитәкчесе булып эшли. 2000 нче елдан бирле,  бүгенге көнгә кадәр Мөслим лицеенда музыка укытучысы, 2017 елдан хәзерге вакытка кадәр  “Ләйсән” балалар бакчасында музыка җитәкчесе  вазыйфаларын башкара.

2008 нче елдан алып музыка рәсем укытучыларының район методик берләшмәсен җитәкли.  2012 нче елдан югары категорияле музыка укытучысы. 2016 нчы елда Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы башлыгының мактау грамотасы, 2020 нче елда Тататарстан Республикасының Мәгариф һәм фән министрлыгының Рәхмәт хаты белән бүләкләнде.



**Галеева Зилә Фәрси кызы** 1967 нче елның 5 нче декабрендә Мөслим районы Яңа Сәфәр авылында дөньяга килә. 1972 нче елда Яңа Сәфәр башлангыч мәктәбенә укырга керә. 1984 нче елда Түбән Кама шәһәрендә лаборант белгечлегенә укып чыга. 1986 нче елда “Ләйсән” балалар бакчасында тәрбияче ярдәмчесе булып эшли башлый,соңыннан хуҗалык мөдире итеп күчерелә.2005 нче елда “Ләйсән”балалар бакчасы ябылу сәбәпле,”Миләшкәй” балалар бакчасына күчерелә. 2008 нче елда “Ләйсән” балалар бакчасы кабаттан ачылгач, Зилә Фәрси кызы яраткан бакчасына эшкә кайта.

Һәм бүгенге көнгә кадәр бакчада хуҗалык мөдире булып хезмәт куя.



**Ганиева Гөлнур Рафаэл кызы** 1972 нче елның 19 нчы февралендә Мөслим районы Метрәй авылында туа. 1989 нчы елда Метрәй 10 еллык мәктәбен тәмамлап, Бөгелмә шәһәре училищесында тегүче һөнәрен үзләштерә. 1991- 92 нче елларда Метрәй мәктәбендә укучыларга тегүче хезмәтенә өйрәтү дәресләре алып бара. 2016 нчы елда “Ләйсән” балалар бакчасында техник эшче булып эшли башлый. Бүгенге көндә бакчада пешекче ярдәмчесе булып хезмәт куя.



**Исанова Лилия Фиргат кызы** 1987 нче елның 9 нчы июлендә Мөслим районы Карамалы авылында туган. Карамалы мәктәбендә 11 еллык белем алып, Чаллы шәһәре ПУ-67 училищесында пешекче һөнәрен үзләштерә. 2007 нче елда Чаллы шәһәрендә пешекче булып эшли.Ә 2015 нче елның май аенда Мөслим “Ләйсән” балалар бакчасында пешекче булып эшли башлый. Бүгенге көндә дә бакчада үз хезмәтен яратып башкара. .



**Назмиева Светлана Карбетдин кызы** 1966 нчы елның 24 нче мартында Мөслим районы Бәләкәй Чакмак авылында туа. Мөслим мәктәбендә урта белемне ала.1987- 1997 нче елларда Мөслим “Кояшкай” балалар бакчасында тәрбияче ярдәмчесе булып эшли.2016 нчы елдан Мөслим “Ләйсән” балалар бакчасында эшли башлый. Бүгенге көндә бакчада эшләвен дәвам итә..



**Юсупова Фәйрүзә Наил кызы** 1966 нчы елның 19 нчы гыйнварендә Мөслим районы Мәллә Тамак авылында туа.1983 нче елны мәктәпне тәмамлап, “Кызыл Октябрь” колхозында эшли. 1984-86 нчы елларда Брежнев шәһәрендәге училищеда кондитер һөнәрен үзләштерә. 1990-99 нчы елларда Мөслим “Миләшкәй” балалар бакчасында пешекче булып эшли. 2001 нче елдан 2013 нче елга кадәр “Ләззәт” кафесында пешекче хезмәтен башкара. 2014 нче елдан бүгенге көнгә кадәр Мөслим “Ләйсән” балалар бакчасында балаларыбызны тәмле ризыклар белән сыйлый.



**Фахразиева Ландыш Җәүдәт кызы** 1982 нче елның 10 нчы ноябрендә Мөслим районы Метрәй авылында туа.Мөслим урта белем бирү мәктәбен тәмамлагач, Чаллы шәһәре профессионал училищесында белем ала.Бик күп еллар кибеттә сатучы булып эшли. 2009 нчы елдан бүгенге көнгә кадәр Ландыш Җәүдәт кызы Мөслим “Ләйсән” балалар бакчасында тәрбияче ярдәмчесе булып эшли .



**Ибраһимова Гүзәлия Мирзасалих кызы** 1955 нче елның 9 нчы сентябрендә Мөслим районы Мөслим авылында туа. 1973-1977 нче елларда Минзәлә педагогик көллиятендә укый. 1977 нче елдан Мөслим “Кояшкай” балалар бакчасында тәрбияче булып эшли башлый. 1988- 2003 нче елларда Мөслим “Ләйсән” балалар бакчасында тәрбияче булып эшли. Тырыш хезмәте өчен 1992 нче елда “Мәгариф отличнигы” һәм күкрәк билгесе белән бүләкләнә. 2003 нче елда Мөслим “Ләйсән”балалар бакчасы ябылу сәбәпле, Гүзәл Мирзасалих кызы коллективы белән хезмәтен Мөслим “Кояшкай” балалар бакчасында дәвам итә. Шуннан лаеклы ялга чыга.



**Садикова Раушания Мөгәмбәр кызы** 1963 нче елда Мөслим авылында туган. 1970 нче елда 1 класска укырга кереп Мөслим урта мәктәбен тәмамлый.

1981 нче елда Мөслим районы Октябрь авылына яңа ачылучы "Ландыш" балалар бакчасына тәрбияче булып эшкә килә. 6 ай эшләгәч, Алабуга культура агарту училищесының китапханәчеләр әзерләү бүлегенә укырга керү сәбәпле, эштән китә. Училищены 1983 нче елда тәмамлап, Мөслим районы Октябрь авылына китапханә мөдире булып эшкә кайта. Шушы авылда кияүгә чыгып ике бала үстерә.

1989 нче елда гаилә хәле буенча Мөслимгә күчеп кайтып, район мәгариф бүлегенең методик кабинетына машинистка булып эшкә урнаша.

1991 нче елның сентябреннан район үзәгендәге "Миләшкәй" балалар бакчасына тәрбияче булып эшли башлый.

1991 нче елның декабрендә районндагы яңа ачылучы “Карлыгач” балалар бакчасына тәрбияче булып эшкә күчә. 1992 нче елда читтән торып БПУ га укырга кереп, аны 1995 нче елда тәмамлый.

1998 нч елдан "Карлыгач" балалар бакчасында тәрбияче ярдәмчесе булып эшли.

2006 нчы елда яңадан тәрбияче булып эшли башлый. 2014 нче елга кадәр коллективны башлангыч профсоюз рәисе булып тора һәм 2013 нче елда Татарстан Республикасының Мәгариф бүлеге профсоюз комитетының Мактау грамотасы белән бүләкләнә.

Эш дәверендә "Ел тәрбиячесе", "Яшел ут" , һәм башка бәйгеләрдә актив катнашып мәгариф бүлегенең күп кенә мактау грамоталары, рәхмәт хатлары белән бүләкләнә.

2018 нче елдан лаеклы ялга китә. 2020 нче елдан “Ләйсән” балалар бакчасына вакытлыча тәрбияче хезмәтен башкара.



**Ризванова Сабира Махубрахман кызы** 1959 нчы елның 25 иче июнендә Сарман районы Сарысаз Тәкермән авылында туган. 1966 нчы елда Сарысаз Тәкермән авылындагы мәктәпкә укырга керә.1976 нчы елда Нөркәй урта мәктәбен тәмамлый. 1976-1978 нчы елларда үз авылында балалар бакчасында мөдир булып эшли. 1978-1981 нчы уку елларында Казан педагогия училищесын тәмамлый. 1981-1985 нче елларда Метрәй балалар бакчасында, 1985-87 нче елларда Мөслим районы Мөслим авылындагы “Аленушка” балалар бакчасында, 1987-2005 нче елларда “Ләйсән”балалар бакчасында тәрбияче булып эшли.

2005-2010 нчы елларда “Миләшкәй” балалар бакчасына күчерелә.

2010-2014 нче елга кадәр, “Ләйсән” балалар бакчасында эшләп лаеклы ялга китә.



**Җиһангирова Диләрә Илдус кызы** 1973 нче елның 11 нче августында туган. Белеме югары, 1995 нче елда Алабуга дәүләт педагогия институтының филология факультетын тәмамлый.

1995-2000 нче елларда Мөслим лицеенда инглиз телен укыта.

2001-2012 нче елларда Саклык банкында эшли. 2007 нче елда Казан шәһәрендәге икътисад, идарә һәм хокук институтының икътисад факультетын тәмамлый.

2013 – 2016 нчы елларда «Лэйсэн» балалар бакчасында тәрбияче булып эшли.

2014 нче елда икътисад, идарә һәм хокук институтында (Казан шәһәре) "Педагогика һәм мәктәпкәчә белем бирү психологиясе" юнәлеше буенча белем ала.

2016 нче елның 8 нче ноябреннән Мөслим авылындагы «Күбәләк» балалар бакчасында өлкән тәрбияче булып эшли. 2016-2017 нче елларда Мөслим районы Мәгариф бүлегенең Мактау грамоталары белән бүләкләнә.



**Мөжипова Дамира Габдулбари кызы** 1961 елның 30 нчы июлендә Кемерово өлкәсенең Киселевск шәһәрендә шахтер гаиләсендә туган. Анда унъеллык мәктәпне тәмамлап ,педагогия училищесына укырга керә.1978-1980 нчы еллар-студент еллары. Балалар бакчасында ике ел эшләгәч, Магнитогорск дәүләт педагогика институтына укырга керә. 1987 нче елда институтны тәмамлага,. ике ел методист булып эшли.
30 елга якын Ташлыяр авылы балалар бакчасында тәрбияче булып эшли. 2012-2014 нче елларда Мөслимнең «Ләйсән»балалар бакчасында тәрбияче булып хезмәтен куя.

Хәзерге көндә Ташлыяр авылы «Ләйсән» балалар бакчасында мөдир булып эшли.



**Хәйбрахманова Энже Фәнис кызы** 1977 нче елның 22 нче мартында Мөслим районы Яңа Сәет авылында туа. Яңа Сәет урта белем бирү мәктәбен тәмамлагач, 1977нче елда Яр Чаллы педагогия көллиятенең башлангыч сыйныф укытучысы бүлеген тәмамлый. 1997 нче елда югары белем алып, Нижнекамск шәһәрендә татар теле һәм әдәбияты укытучысы булып эшли башлый.

2000-2001 нче елларда Мөслим районы Мари Буләр авылы урта белем бирү мәктәбендә, 2001-2003 нче елларда Үрәзмәт авылы мәктәбендә балаларга белем бирә. 2003 – 2015 нче елларда Мөслим районы “Наз” балалар приютында хезмәтен куя.2016 - 2018 нче елларда Мөслим “Ләйсән” балалар бакчасында тәрбияче булып эшли.



**Шаяхметова Зөһрә Вәзир кызы** 1983 нче елның 20 нче маенда Мөслим районы Мәллә – Тамак авылында, колхозчылар гаиләсендә өченче бала булып дөньяга килә. Мәллә – Тамак урта мәктәбендә белем ала. Мәктәпне тәмамлагач, Минзәлә авыл хуҗалыгы техникумында бухгалтер – экономист һөнәрен үзләштерә. Техникумны тәмамлагач, Мәллә – Тамак авылы мәдәният йортында мөдир булып эшли. 2006 нчы елда Мөслим авылы 60 нчы номерлы Үзәк даруханәсенә эшли. . Читтән торып Минзәлә шәһәре педагогия көллиятенә укырга керә. 2010 нчы елда Мөслим авылы “Ләйсән” балалар бакчасына эшкә килә. 1 ай тәрбияче ярдәмчесе булып эшләгәннән соң, мәктәпкә әзерлек төркеменә алмаш тәрияче итеп билгеләнә. 2014 нче елда “Карлыгач” балалар бакчасына эшкә күчә, бер ел тәрбияче булып эшләгәннән соң, өлкән тәрбияче итеп билгеләнә. Бүгенге көндә дә “Карлыгач” балалар бакчасында хезмәт куя.



**Зиннурова Зөлфия Шәрәфид кызы** 1961 нче елның 17 нчы гыйнварендa Целиноград төбәге Әстерханка авылында туган. Целеноград медицина училищесында белем ала .1983 нче елда Татарстанга күчеп кайта.1983-1991 нче елларда Метрәй авылы балалар бакчасында , 1991-1996 нчы елларда Мөслим “Тиенкәй”балалар бакчасында, 2001-2016 нчы елларда Мөслим “Кояшкай” балалар бакчсында эшли.

2001 нче елдан Мөслим “Ләйсән” балалар бакчасында төп шәфкать туташының чираттагы ялы вакытларында аның вазифаларын башкара. Хәзерге көндә лаеклы ялда.



**Чернова Лениза Шәйхенур кызы** 1959 нчы елның 17 нче августында Актаныш районы Адай авылында туа. 1981 нче елда Алабуга медицина училищесын тәмамлап,Мөслим Үзәк шифаханәсенә юллама белән эшкә кайта,ашыгыч ярдәм бүлегенә эшкә урнаша, анда лаеклы ялга чыкканчы эшли. Лаеклы ялга чыккач, 2017 нче елның 1 нче июненнән Мөслим “Ләйсән” балалар бакчасына шәфкать туташы булып эшкә килә.Бүгенге көндә дә бакчада намуслы хезмәтен башкара.



**Дусадбекова Асия Әхәт кызы** 1964 нче елның 15 нче гыйнварендa Мөслим районы Краснояр авылында туа.

1971 нче елны Краснояр башлангыч мәктәбенә укырга керә.

Гомуми белемне күрше авылда үзләштерү каралганлыктан, башлангыч мәктәпне тәмамлаганнан соң сыйныфташлары белән берлектә, 1975 нче елны укуын Симәк урта мәктәбендә дәвам итеп, 1981 нче елны тәмамлый.

1981 нче елны Урәзмәт балалар бакчасында тәрбияче булып эшли башлый. Читтән торып Казан педогогия институтна укырга керә.

1982 нче елдан Ташъелга балалар бакчасында бер ел тәрбияче, 3 ел бакча мөдире булып эшли.

1986 нчы елдан Мөслим авылы ,,Алёнушка” балалар бакчасында тәрбияче булып эшли.

1996 нчы елны Бөгелмә педогогия училищесына укырга керә.

1997 нче елда “Айгөл” балалар бакчасы белән, “Миләшкәй” балалар бакчасы берләшү сәбәпле, эшен “Миләшкәй” балалар бакчасында дәвам итә. Лаеклы ялга киткәнче, 2019 нчы елга кадәр, “Миләшкәй” балалар бакчасында эшли.

“Балалар бакчасында мин эшләгән чорда балалар бик куп йөрде, бу эти – әниләр белән бердәм булып, бергә эшләүнең нәтиҗәсе. Балалар өчен уенчыкларны, дәрес өчен сирәк булган материалларны үзебез кулдан ясый идек, эти – әнилэр дә безгә, бик теләп ярдәм иттеләр,”- ди Асия ханым. 2020 нче елдан Мөслим “Ләйсән” балалар бакчасына вакытлыча тәрбияче ярдәмчесе булып эшли.



**Назмиева Алсу Тәлгать кызы** 1994 нче елның 26 нчы августында Мөслим авылында туа. Мөслим районы гимназия мәктәбен тәмамлагач, Чаллы педагогия көллиятенә укырга керә. 2015 нче елны укуын тәмамлап, Алабуга педагогия университетында читтән торып укый.2018-2020 нче елларда “Ләйсән” балалар бакчасында техник эшче хезмәткәр булып эшли.Хәзерге көндә Чаллы шәһәрендә яши.



**Латипова Флүрә Вильдан кызы** 1952 нче елның 12 нче сентябрендә Мөслим районы Мөслим авылында туган.

1961 нче елда Мөслим урта мәктәбенә укырга керә.1971 нче елда урта мәктәпне тәмамлап, ипи пешерү комбинатына эшкә урнаша.

1972-1973 нче елларда Мөслимнең гидрометеостанциясендә эшли.

1971-1977 нче елларда ипи пешерү комбинатында эшли.

1977 нче елда Мөслимнең 2 номерлы балалар бакчасында кече тәрбияче булып эшкә урнаша.

1987-2003 нче елларда “Ләйсән” балалар бакчасында тәрбияче ярдәмчесе булып эшли. Хәзерге көндә лаеклы ялда.



**Ильясова Мөнҗия Нурлыгаян кызы** 1963 нче елның 16 нчы февралендә Актаныш районы Пучы авылында туа. 1970-1980 нчы елларда Пучы урта мәктәбен тәмамлый.

1988-1989 нчы уку елларында , “Ләйсән балалар бакчасында тәрбияче ярдәмчесе ; 2002 – 2005 нче елларда пешекче һөнәрен булып эшли. Хәзерге көндә лаеклы ялда.



**Валиева Рәмзия Исрафил кызы** 1955 нче елның 1 нче августында Мөслим районы Иске Чакмак авылында туган. 1987 нче елның 30 нчы ноябрендә «Ләйсән» балалар бакчасында кече тәрбияче булып эшли. 2005 нче елда “Ләйсән”балалр бакчасы ябылу сәбәпле «Кояшкай » балалар бакчасына күчерелә, лаеклы ялга чыкканчы, шунда эшли.



**Закирова Гөлнур Ягъфәр кызы** 1959нчы елның 5 нче январендә Перм өлкәсе Гремячинск шәһәрендә туган.

1996 нчы елны Иске Вәрәш авылының башангыч мәктәбен, 1976 нчы елны Мөслим урта мәктәбен тәмамлый. 1987-2005-2014 нче елларда Мөслим районы “Ләйсән” балалар бакчасында тәрбияче ярдәмчесе булып эшли башлый. 2014 нче елдан лаеклы ялда.



**Фәрхетдинова Гөлнар Валериянт кызы** 1985 нче елның 15 нчы декабрендә Мөслим авылында дөньяга килэ. 2004-2007 нче елларны Алабуга мәдәният училищесын тәмамлап, театр коллективы җитәкчесе квалификациясе бирелә. 2011 нче елны Әлмәт шәһәренең ВЭГУга керә, башлангыч класс җитәкчесе белгечлеген ала. 2007-2013 нче елларны Мөслим почта үзәгендә кассир булып эшли. 2014-2015 нче елларда “Ләйсән” балалар бакчасында тәрбияче ярдәмчесе булып эшли. Хәзерге көндә мәдәният бүлегендә эшли.



**Асманова(Сабирова) Раушания Маркс кызы** 1967нчы елнын 23 нче февралендэ Мөслим районы Бикмәч авылында туган. Бикмәч башлангыч мәктәбендә, 1978-1982 нчы елларда Яна-Усы сигезъеллык мәктәбендә укый. 1982-1984 нче елларда Мөслимдә укый. 2010-2015 нче елнын Мөслим «Ләйсән» балалар бакчасында тәрбияче ярдәмчесе булып эшли. Хәзерге лаеклы ялда.



**Галимова Рәмилә Назим кызы** Казан педагогия институтын тәмамлагач, 1994 нче елның 15 нче августыннан хезмәт юлын Баек урта мәктәбендә татар теле әдәбияты һәм тарих укытучысы булып эшли башлый. 1996 нчы елдан ПУ-94 тә эстетика, тарих фәннәре укытучысы , укыту эшләре буенча директор урынбасары вазыйфасын башкара. 2008 нче елның 13 нче августыннан Мөслим “Ләйсән” балалар бакчасы мөдире, 2011нче елдан ООО “Мост” җәмгыяте директоры булып билгеләнә.



**Валиуллина Айзирә Илдус кызы** 1980 нче елның 14 нче июнендә Мөслим районы Симәк авылында туа. 1997 нче елны урта белем бирү мәктәбен тәмамлап,1998 нче елда Чаллы педагогия көллиятенә укырга керә. 2005- 2008 нче елларда Зәй шәһәре балалар бакчасында эшли.2008 нче елда Мөслим “Ләйсән” балалар бакчасына тәрбияче булып килә, 2011-2016 нчы елларда бакча мөдире булып эшли. 2017 нче елдан Мөслим “Миләшкәй” балалар бакчасында тәрбияче булып эшли башлый.



**Фазлыева (Сабитова) Гөлнур Фәрит кызы** 1977нче елның 3 нче апрелендә Мөслим районы, Мөслим авылында туган. Мөслим урта мәктәбен тәмамлагач, Яр Чаллы педагогия институтының мәктәпкәчә тәрбия бирү бүлегендә белем ала.

2001 нче елда тәрбияче ярдәмчесе булып педагогик хезмәт юлын башлап җибәрә.

2003-2006 нче елларда «Миләшкәй», «Ләйсән» балалар бакчаларында, 2006-2012 нче еллар арасында Мөслим мәктәптән тыш эшләр үзәгендә педагог-психолог булып эшли.

2012-2014 нче елларда «Ләйсән» балалар бакчасында вакытлыча бакча мөдире итеп билгеләнелә.

2014 нче елдан «Карлыгач» балалар бакчасы мөдире булып эшли.



**Мөхмәтова Резеда Рәшит кызы** 1978 нче елның 11 нче маенда Мөслим районы Метрәй авылында туган. 1985-1988 нче елларда Метрәй урта мәктәбендә, 1989-1995 нче елларда Мөслим урта мәктәбендә белем ала.

1995-1999 нчы елларда КДПУ ның татар теле һәм әдәбияты бүлегендә укый.

1999-2001 нче елларда Михайловка урта мәктәбендә татар теле һәм әдәбияты укытучысы булып эшли.

2003-2005 нче елларда Мөслим “Ләйсән” балалар бакчасына тәрбияче итеп күчерелә. 2005 нче елда “Ләйсән “балалар бакчасы ябылу сәбәпле, Мөслим “Кояшкай” балалар бакчасына тәрбияче итеп күчерелә. 2005-2016 нчы елларда Мөслим “Кояшкай” балалар бакчасында тәрбияче булып эшли .”Ел тәрбиячесе -2014” конкурсында катнашып муниципаль турда Гран –Прига ия була. Даими рәвештә “Салават күпере” журналында, “Ачык дәрес”, “Авыл утлары” гәҗитләрендә авторлык мәкаләләре басылып чыга. Тәрбияләгән балалары “Йолдызлык”, “Яшь бөреләр” конкурсларында җиңүләр яулыйлар. Бакчада “Әхлак дәресләре”, “Юл йөрү кагыйдәләренә өйрәтү” буенча методик ярдәмлекләр эшләүдә катнаша. Тырыш хезмәте өчен Мөслим районы Мәгариф бүлегенең мактау кәгазьләре, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының Дипломы белән бүләкләнә.

2016 нчы елның 20 нче октябреннән Резеда Рәшит кызы Мөслим “Ләйсән” балалар бакчасына мөдире итеп билгеләнә. 2 ай эшләгәч, 1 декабрьдән “Ләйсән”балалар бакчасы капитаь ремонтка туктый. 6 ай дәвамында Мөслим төзелеш оешмасы (МСО ) көче белән бакча, тарихка язарлык зур ремонт кичерә. 2017 нче елда бакча ТР Мәгариф хезмәткәрләренең август киңәшмәсе кунакларын кабул итә. Коллектив районкүләм, республика күләм үткәрелгән барлык чараларда да актив катнашып,алгы рәтләрдә бара.

Резеда Рәшит кызы бүгенге көндә дә үзенең коллетивы белән кулга –кул тотышып, алга куелган максатларга ирешү өчен, бөтен тырышлыгын куеп хезмәт итә.



**Салихова Гөлназ Нәҗметдин кызы** Салихова Гөлназ Нәҗметдин кызы 1987 елның 8 августында Мөслим районы Салауз-Мухан авылында, гаиләдә беренче бала булып туа . Мухан төп гомуми мәктәбен тәмамлагач , Бөгелмә педагогия көллиятенә, инглиз телләрен өйрәтү факультетына укырга керә. Кечкенәдән белемгә омтылуы, тырышып укуы, мәктәп программасы нигезләрен тирәнтен үзләштерүе аны шушы өлкәгә тарта. Мөгаллимлек һөнәрен якын итә ул. 5 ел белем алгач, югары белем алырга читтән торып Яр Чаллы педагогия институтына укырга керә. 7 ел мәктәптә инглиз теле укытканнан соң, Мөслим “Ләйсән”балалар бакчасына өлкән тәрбияче булып билгеләнә. Гөлназ Нәҗметдин кызы 2017 елда беренче категориягә ия була. Район һәм республика күләмендә оештырылган конкурсларда үзе дә, педагоглары да актив катнаша: “Гаиләгә юл” муниципаль конкурсында 1 урын; Юл хәрәкәтен өйрәтү буенча “Яшел ут” конкурсында 2 урын; “Бизиборд” конкурсында 1 урын; “Иҗади шәһес” бәйгесендә 2 урын; 3 ел рәттән (2017-2019 еллар) тәрбиячеләре дә “Ел тәрбиячесе” конкурсында, “Сәяр”, “Яшел ут” бәйгеләрендә призлы урыннарга лаек булдылар. Район күләмендә оештырылган смотр конкурсларында, җәмәгать эшләрендә, спартакиада бик теләп катнаша. Тырыш хезмәте өчен Мөслим районы Мәгариф бүлегенең мактау кәгазе белән бүләкләнә. Бүгенге көндә дә бакчада хезмәтен куя.



**Зиннурова Алия Таhир кызы** 1986нче елның 9 нче сентябрендә Мөслим районы,Мөслим авылы туган. 2009 нче елда Яр Чаллы шәһәре педагогия институтының “Мәктәпкәчә яшьтәге балаларга белем бирү” бүлеген читтән торып тәмамлый. 2008 нче елның 1 нче ноябреннән бүгенге көнгә кадәр Мөслим районы “Ләйсән” балалар бакчасында тәрбияче булып эшли .



**Абдреева Гөлназ Фадаэль кызы** 1981 нче енын 6 нчы мартында Мөсим авылында туган. 1987-1998 нче елларны урта мәктәпне тәмамлый. 1998-2001 нче елларда Бөгелмә педагогия училищесының Филология факультетын бетереп кайткач, ПУ-94 училищесының бухгалтер курсларын кызыл дипломга тәмамлый. Шул ук елны Мөслим урта мәктәбенә лаборант булып эшкә керә. 2008 нче елны “Ләйсән” балалар бакчасында кече тәрбияче булып эшли башлый. 2009 нчы елны читтән торып НГПИ ның “Мәктәпкәчә яшьтәге балаларга белем бирү” бүлеген тәмамлый. 2011 нче елны тәрбияче итеп билгеләнә. Бик күп конкурсларда катнашып, төрле матбугатларда бастырылган материаллар өчен мактау грамоталары һәм дипломнар белән бүләкләнә.

2008 нче елдан бүгенге көнгә кадәр “Ләйсән” балалар бакчасында тәрбияче булып хезмәт куя. Эшләү дәверендә Гөлназ Фадаэль кызы төрле район һәм республикакүәм конкурсларда катнашып район Мәгариф бүлегенең Мактау грамотасы, Рәхмәт хатлары һәм Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының таныклыгы белән бүләкләнде. (2013, 2017, 2018, 2019 нчы елларда “Ел тәрбиячесе” конкурсына катнашып мәгариф идарәсенең Мактау грамотасы һәм Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының «Ел тәрбиячесе» республика һөнәри конкурсында катнашкан өчен таныклыгы белән бүләкләнде. Юл хәрәкәтен өйрәтү буенча “Яшел ут”, “Әкият мотивында коврабук”, “Бизиборд” конкурсында катнашып диплом һәм грамоталар иясе. “Сәйяр” театр конкурсында Мәгариф һәм фән министрлыгының дипломына лаек булды. Бик күп материаллары төрле газета, журналларда бастырылып чыкты (“Мәгариф”, “Фән һәм мәктәп”, “Ачык дәрес” журналлары, “ФДБББС призмасы аша мәктәпкәчә белем бирү” җыентыгы, Бөтенроссия фәнни-гамәли конференциясе материаллары җыентыгы). Югары категорияле Гөлназ Фадаэль кызы бүгенге көндә дә Мөслим “Ләйсән” балалар бакчасында хезмәт куя.



**Идиятуллина (Габбасова) Алия Фирдвес кызы** 1989 нче елның 19 нчы апрелендә Мөслим районы Салавыз-Мухан авылында туган. Туган авылында урта мәктәпне тәмамлагач, Яр Чаллы дәүләт педагогия институтының мәктәпкәчә тәрбия бирү педагогикасы һәм психологиясе факультетын тәмамлаган.

2016 нче елның 19 нчы гыйнварында Мөслим үзәгендә урнашкан «Ләйсән» балалар бакчасына педагог-психолог буларак эшкә килә. Бераз соңрак тәрбияче булып эшли башлый.



**Сарварова Гөлназ Рамил кызы** Мөслим районы Ташьелга авылында 1988 нче елның 17 нче маенда туа.Мәктәпне тәмамлагач, Алабуга педагогия университетында биология укытучысы белгечлеге ала. Югары белемле укытучы Мөслим районы Баек авылына мәктәпкә эшкә кайта. 2011 нче елда Мөслим “Ләйсән” балалар бакчасында тәрбияче булып тырыш хезмәтен куя.



**Гилазова Лариса Анатолий кызы** 1984 нче елның 18 февралендә Мөслим районы Яңа Усы авылында туа. 1990-2001 нче елларны Яңа Усы урта мәктәбен тәмамлый. 2009 нчы елда Мөслим районы “Ләйсән” балалар бакчасына техник хезмәткәр булып эшкә килә, 2010 нчы елда өлкән пешекче итеп билгеләнә. 2015 нче елдан тәрбияче ярдәмчесе, 2018 нче елда вакытлыча педагог – психолог булып эшли.



**Нуруллина Альбина Индус кызы** нче елның 14 нчемартында Актаныш районының Актаныш авылында дөньяга килә.

Мәктәпне тәмамлагач, 1994 нче елны Минзәлә педагогия көллиятенә укырга керә.1997 нче елны тәмамлап, Түбән Камага эшкә китә. 2010 нче елда “Ләйсән” балалар бакчасына тәрбияче булып эшкә керә. Бүгенге көндә дә шушы бакчада балаларга белем һәм тәрбия бирә.



**Ногманова Ләйсән Фәрид кызы** 1983 елның 22 нче сентябрендә Мөслим районы Метрәй авылында туа. 1991-2002 нче елларда Метрәй төп гомуми белем бирү мәктәбендә укый. 2002-2006 нчы елларда Түбән Кама педагогия училищесында башлангыч класс һәм татар теле укытучысы һөнәрен үзләштерә. 2013 нче елда бүгенге көнгә кадәр «Ләйсән» балалар бакчасында тәрбияче ярдәмчесе булып эшли.



**Халиуллина Алсу Илдус кызы**, 1996 нчы елның 2 нче ноябрендә, Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәрендә туган. 2014 нче елны Мөслим икенче урта мәктәбен тәмамлаган.

2014-2018 нче елларда Яр Чаллы дәүләт педагогика университетының, «Педагогика һәм психология» факультетында белем ала.

2020 нче елның октябреннән Мөслим «Ләйсән» балалар бакчасында вакытлыча тәрбияче вызыйфаларын башкара.



**Садикова Ландыш Рафис кызы** 1994нче елның 27 нче июнендә Мөслим районы Ташлияр авылында туа. 2001 нче елда Ташлыяр төп гомуми белем бирү мәктәбенә укырга керә. 2010 нчы елда 9 нчы классны тәмамлап, Мөслимдәге ПУ-94 училищесына повар- кондитер бүлегенә укырга керә. 2013 нче елда училищены тәмамлап, "Дуслык" кафесында повар- кондитер булып эшли башлый. 2018 нче елда "Карлыгач" балалар бакчасында ишегалды җыештыручысы булып эшли.

2020 нче елдан "Ләйсән " балалар бакчасында тәрбияче ярдәмчесе булып эшли.



**Ахметвалиева Гөлнара Мәхтум кызы** 1990 нчы елның 16 нчы июнендә Мөслим районы Торыш авылында туа.Симәк урта мәктәбендә 11 классны тәмамлап, 2007-2010 нчы елларда Әлмәт шәхәрендәге Сәүдә Икътисад техникумында белем ала. 2015 елда Мөслим «Күбәләк» балалар бакчасында тәрбияче ярдәмчесе булып эшли. 2020 нче елдан вакытлыча «Ләйсән» балалар бакчасында тәрбияче ярдәмчесе вазыйфаларын башкара.